# Казна байлыгы бөртеклəп җыела

## Федераль казначылык Идарəлеге оештырылуга 25 ел тула



**Казначылык хезмəте тамырлары белəн Борынгы Рус дəүлəтенə барып тоташа. Ул чорда ук кнəзлəрнең байлыгын саклау һəм барлау максатыннан казначы вазифалары булдырыла. Рус дəүлəтенең җир билəмəлəре арту сəбəпле, казна байлыклары да үсə. Шул рəвешле 15 гасырда Казначылык йортлары барлыкка килə һəм бу хезмəтнең əһəмияте арта. 18 гасырда дəүлəтнең финанс системасын үстерүгə юнəлтелгəн Петр I һəм Екатерина II боерыклары казначылыкны үстерүгə этəргеч була. 1918 елда əлеге системаның вəкалəтлəре яңа финанс органнарына йөклəтелə.**

1992 елның 8 декабрендa Русия Федерациясе Президенты Б.Ельцин боерыгы белəн Финанс Министрлыгы составында Федераль казначылык Идарəлеге төзелə. Бу дата тарихка Казначылык хезмəткəрлəре көне буларак кереп кала. Чирек гасыр тарихы булган Идарəлек хезмəтенең җəмгыятьтə əһəмияте зур. Касса операциялəре үткəрү, бюджет түлəлешен тикшерү, кануннарда билгелəнгəн нормативларга ярашлы төрле дəрəҗəдəге бюджетлар арасында керемнəрне бүлү, Федераль һəм урындагы бюджетлар түлəлешендə касса хезмəтлəре күрсəтү, бюджет түлəлеше хакында вакытлы һəм сыйфатлы хисап бирү кебек мөһим мəсьəлəлəр Федераль казначылык Идарəлеге һəм бүлеклəренə йөклəтелгəн. Казначылык, идарə итүнең яңа сыйфатларын кертүче буларак, дəүлəткүлəм мəгълүмат системаларының операторы функциясен үти.

Интернетның көнкүрешкə тыгыз бəйлəнеше сəбəпле, Идарəлек хезмəткəрлəре "Дəүлəт һəм муниципаль түлəүлəр", "Идарə" дəүлəт автоматлаштырылган мəгълүмат системалары, сатып алулар өлкəсендəге Бердəм мəгълүмат системасы рəсми сайты, "Электрон бюджет" җəмгыять финанслары белəн идарə итү дəүлəт интеграль мəгълүмат системасы кебек чараларны кулланышка кертү һəм камиллəштерү юнəлешендə эйдəүче булып тора.

Борай районы җирлегендə Федераль казначылык функциялəрен Башкортстан Республикасы Федераль казначылык Идарəлегенең 17нче Бүлеге башкара. Бүгенге көндə бүлек төрле дəрəҗəдə финанслану чы 17 учреждениене: район эчке эшлəр бүлеге, суд приставлары, Пенсия фонды, район финанс идарəлеге һəм 13 муниципаль авыл билəмəсен хезмəтлəндерə. Шулай ук 2015 елдан башлап, бюджет процессына катнашы булмаган тугыз оешманың (ветстанция, мəгълүмат-консультация үзəге, балалар-үсмерлəр спорт мəктəбе, район-мəдəният йорты һ.б.) халыкка күрсəткəн хезмəттəн керемнəре безнең счетлар аша үткəрелə. Төрле мəгълүмат системаларында теркəлгəн, безнең тарафтан хезмəт күрсəтелүче 53 оешмага даими рəвештə электрон-цифрлы имзалар əзерлəп бирелə. Казначылык идарəлеге аша үткəн керемнəрдə районның алга үсеше дə чагыла. Мəсəлəн, əлеге вакытта крестьян-фермер хуҗалыкларын үстерүгə юнəлтелгəн Федераль программада каралган авыл җитештерүчелəренə тəгаенлəнүче грантлар Бүлек аша җиткерелə. Безнең районда быел Даутлардан Флорис Шакиров, Ялдəктəн Раил Ахунов, Шабайдан Гөлназ Диярова бу грантларның иялəре булды.

Бүлектə вазифаларны башкару югары квалификацияле белгечлəргə йөклəтелгəн. Өлкəн казначей Зилə Шəртдинова, казначей Ирина Шаһиева, беренче разрядлы белгеч Эмма Нуртдинова үз вазыйфаларын зур җаваплылык белəн башкара, системага кагылышлы үзгəрешлəргə ярашлы белемнəрен даими камиллəштереп тора. Заманча технологиялəрне актив кулланып, югары һөнəри осталыкка ирешкəннəре өчен Идарəлекнең Мактау грамоталары, Рəхмəт хатларына лаек булдылар. Якынлашып килгəн юбилей уңаеннан районда казначылык хезмəтенең формалашу дəверендə һəм бүгенге көндə эшлəүче хезмəткəрлəрне бəйрəм белəн котлап, районыбызның финанс торышын ныгытуда уңышлар телим.

**Ф. ƏҮХƏТОВА,**
**Федераль казначылык Идарəлегенең район бүлеге начальнигы.**